


экосәхифә

# ХӘТЕРСЕЗ ТИЕН



**СӘЛАМ, МАЛАЙЛАР ҺӘМ КЫЗЛАР! ТАНЫШ БУЛЫЙК: ИСЕМЕМ – АЙЗИЛӘ. ТАБИГАТЬНЕ СӨЮЧЕ ТАТАР КЫЗЫ МИН. ШУҢА ДА КАЗАНДАГЫ ЭКОЛОГИЯ ЮНӘЛЕШЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ 79 НЧЫ ЛИЦЕЙНЫ САЙЛАДЫМ.**

## Беләә идеңме?

Горки-Әмәт урманында тиеннәр яшәвен беләә идеңме? Без аларны уку елы башыннан ук күзәтәбез. Кыш айларында сыйныфыбыз белән тиеннәргә җимлекләр дә ясадык.

## Сан

Тиен көненә 100 нарат күркәсе ашый ала.

## Фәнни мәгълүмат

Тиен – кимерүчеләр отрядына караган, урманнарда да, шәһәр паркларында, дала һәм чүлләрдә дә очрый торган затлы тунлы бик матур хайван. Ул кышка дип әллә никадәр агач орлыгы җыя да, кая куйганын оныта икән. Онытылган орлыклардан исә меңләгән агач үсеп чыга. Тиен – иң шәп урман үстерүче булып чыга түгелме?!

## Бүләкле булыйм, дисәң...

Тиен турында шигъри юллар яз да, аны тиз генә sabantui@bk.ru адресына җибәр. Беренче җавап юллаучыга 79 нчы лицейдан кәттә бүләк!

